МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

№ 309/о

«18» 03 2025

БОЕРЫК

«Гомумзавод технологик торбаүткәргечләре, парүткәргечләре белән эстакада, ТФК-1000 җайланмасын тит.070(0914) (тит.067/5(9903)) белән тоташтыру» линия объектын урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне ызанлау проектын раслау турында

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 43, 45 һәм 46 статьялары, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Территорияне планлаштыру проектын әзерләү турында» 2024 елның 24 маендагы 140/о номерлы боерыгы нигезендә, 2024 елның 230 декабрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, боерык бирәм:

1. «Гомумзавод технологик торбаүткәргечләре, парүткәргечләре белән эстакада, ТФК-1000 җайланмасын тит.070(0914) (тит.067/5(9903)) белән тоташтыру» линия объектын урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне ызанлау проектын расларга (кушымтада бирелә).

2. Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсенең Кама агломерациясен үстерү бүлегенә (В.В.Бельскийга) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрүне;

әлеге боерыкны үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

әлеге боерыкны «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып җиде эш көне эчендә урнаштыруны.

3. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А.Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары В.Н.Кудряшев

Министерство строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан * Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы *
Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 18.03.2025 ел, №309/о боерыгы белән расланды

# «Гомумзавод технологик торбаүткәргечләре, парүткәргечләре белән эстакада, ТФК-1000 җайланмасын тит.070(0914) (тит.067/5(9903)) белән тоташтыру» линия объектын урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру проекты

«Недвижимость» кадастр үзәге»
ҖАВАПЛЫЛЫГЫ ЧИКЛӘНГӘН ҖӘМГЫЯТЕ

ОГРН 1 121644000664, ИНН 1644064485, КПП 164401001,
Адресы: Әлмәт шәһ., Герцен ур., 88 й., 74; тел: (8553) 43-28-84, e-mail:oookcn@ya.ru

**Заказ бирүче:** В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ
**Башкаручы**: «Недвижимость» кадастр үзәге» ҖЧҖ

# «Гомумзавод технологик торбаүткәргечләре, парүткәргечләре белән эстакада, ТФК-1000 җайланмасын тит.070(0914) (тит.067/5(9903)) белән тоташтыру» объектының планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты

**Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы, «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге**

«Недвижимость» кадастр үзәге»
ҖЧҖ директоры / Р.Г.Галәвов/

Әлмәт 2024

**Территорияне планлаштыру документациясе составы**

| т/с | Составы | Атамасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | Территорияне планлаштыру проектының төп өлеше | 1 бүлек. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеше | |
| | | 2 бүлек. Линия объектларын урнаштыру турында нигезләмә | |
| 2 | Территорияне планлаштыру проектын нигезләү материаллары | 3 бүлек. Территорияне планлаштыру проектын нигезләү буенча материаллар. График өлеше | Китерелми |
| | | 4 бүлек. Территорияне планлаштыру проектын нигезләү буенча материаллар. Аңлатма язуы | Китерелми |
| 3 | Территорияне ызанлау проектының төп өлеше | 5 бүлек. Территорияне ызанлау проекты. График өлеше | |
| | | 6 бүлек. Территорияне ызанлау проекты. Текст өлеше. | |
| 4 | Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары | 7 бүлек. Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары. График өлеше | Китерелми |
| | | 8 бүлек. Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары. Аңлатма язуы. | Китерелми |
| 5 | Кушымталар | | Китерелми |

## ЭЧТӘЛЕК


| т/с | Атамасы | Искәрмә |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | **Кереш** | |
| 1 | **1 бүлек. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеше** | |
| 1.1-1.3 | Кызыл линияләр сызымы; линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләре сызымы; урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләре сызымы. | |
| 2 | **2 бүлек. Линия объектларын урнаштыру турында нигезләмә** | |
| 2.1 | Урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларының, шулай ук линия объектларының атамасы, төп характеристикалары (категориясе, озынлыгы, проект куәте, үткәрү сәләте, йөк көчәнеше, хәрәкәт интенсивлыгы) һәм билгеләнеше | |
| 2.2 | Территорияләрендә линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары билгеләнә торган Россия Федерациясе субъектлары исемлеге, Россия Федерациясе субъектлары составындагы муниципаль районнар, шәһәр округлары исемлеге, федераль әһәмияттәге шәһәрләрнең җирлекләре, торак пунктлары, шәһәр эчендәге территорияләре исемлеге | |
| 2.3 | Линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге | |
| 2.4 | Линия объектларының урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. | Планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрендә линия объектлары составына керүче капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрлары | |
| 2.6. | Территорияне планлаштыру проектын әзерләү вакытына гамәлдә булган һәм төзелә торган капиталь төзелешнең сакланып калучы объектларын (бинаны, төзелешне, корылманы, төзелеп бетмәгән объектларны), шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документация нигезендә төзүгә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларын линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат | |
| 2.7. | Линия объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклап калу чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат | |
| 2.8 | Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат | |
| 2.9 | Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат | |
| **3** | **3 бүлек. Территорияне планлаштыру проектын нигезләү буенча материаллар. График өлеше** | |
| 3.1 | Планлаштыру структурасы элементларының (линия объектлары биләгән һәм (яисә) линия объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән территорияләрнең)урнашу схемасы | |
| 3.2 | Территорияне планлаштыру проектын әзерләү чорында территориядән файдалану схемасы | |
| 3.3 | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре схемасы | |

| | | |
|---|---|---|
| 3.4 | Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр (янгын, шартлау, химик, радиоактив зарарлану, су басу, су бастыру, ишелү, карстлар, эрозия һ.б.) килеп чыгу куркынычы янаган территорияләр чикләре схемасы | |
| 3.5 | Конструктив һәм планлаштыру чишелешләре схемасы | |
| **4** | **4 бүлек. Планлаштыру проектын нигезләү материаллары. Аңлатма язуы** | |
| 4.1 | Территорияне планлаштыру проекты эшләнә торган территориянең табигый-климат шартларын тасвирлау | |
| 4.2 | Линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләүне нигезләү | |
| 4.3 | Урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләүне нигезләү | |
| 4.4 | Линия объектлары составында проектлана торган капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрендә территориядә төзелеш алып баруның чик параметрларын билгеләүне нигезләү | |
| 4.5 | Территорияне планлаштыру проектын әзерләү вакытына гамәлдә булган һәм төзелә торган капиталь төзелешнең сакланып кала торган объектлары (бина, төзелеш, корылма, төзелеше тәмамланмаган объект) белән линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләре кисешүләренең җыелма исемлеге | |
| 4.6 | Линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең төзелеше территорияне планлаштыру буенча элек расланган документлар нигезендә планлаштырылган капиталь төзелеш объектлары белән кисешүләре җыелма исемлеге | |
| 4.7 | Линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең су объектлары (шул исәптән су агымнары, сулыклар, сазлыклар һ.б.) белән кисешүләренең җыелма исемлеге | |
| 5 | **5 бүлек. Территорияне ызанлау проекты. График өлеше** | |

| | | |
|---|---|---|
| **6** | **6 бүлек. Территорияне ызанлау проекты. Текст өлеше.** | |
| **6.1** | Барлыкка килә торган (үзгәртелә торган) җир кишәрлекләре исемлеге | |
| **6.2** | Барлыкка килә (үзгәртелә) торган җир кишәрлекләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге | |
| **6.3** | Территория чикләре турында белешмәләр | |
| **6.4** | Барлыкка килә торган (үзгәртелә торган) җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре | |
| **7** | **7 бүлек. Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары. График өлеше** | |
| **8** | **8 бүлек. Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары. Аңлатма язуы** | |
| **8.1** | Барлыкка килә торган (үзгәртелә торган) җир кишәрлеге чикләренең урнашу урынын билгеләүне барлыкка килә торган җир кишәрлекләренә карата таләпләрнең, шул исәптән җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь) зурлыкларына карата таләпләрнең үтәлешен исәпкә алып нигезләү | |
| **8.2** | Җир кишәрлеген барлыкка китерү (үзгәртү) ысулын нигезләү | |
| **8.3** | Барлыкка килә торган (үзгәртелә торган) җир кишәрлегенең үлчәмнәрен билгеләүне нигезләү | |
| **8.4** | Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнергә тиешле гавами сервитут чикләрен билгеләүне нигезләү | |
| **9** | **Кушымталар** | |

# КЕРЕШ

Территорияне планлаштыру документларын әзерләү Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Территорияне планлаштыру проектын әзерләү турында» 24.05.2024 ел, №140/о боерыгы нигезендә «Гомумзавод технологик торбаүткәргечләре, парүткәргечләре белән эстакада, ТФК-1000 җайланмасын тит.070(0914) (тит.067/5(9903)) белән тоташтыру» линия объектларын урнаштыру өчен башкарыла. Әлеге проект линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналарының чикләрен билгели. Территорияне планлаштыру проекты составында территорияне ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла.


Объектны «Татарстан Республикасының Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә урнаштыру планлаштырыла. Проектны гамәлгә ашыру өчен торак пунктлар җирләре, урман фонды җирләре һәм сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика җирләре, космик эшчәнлекне тәэмин итү җирләре, оборона, иминлек җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр файдаланылачак.

Территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты составына карата төп норматив таләпләр түбәндәге норматив документлар белән билгеләнгән: Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бер яисә берничә линия объектын урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру документациясенең составы һәм эчтәлеге турындагы нигезләмә раслау хакында» 2017 елның 12 маендагы 564 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 27 декабрендәге 3134-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Татарстан Республикасында территорияне планлаштыру проектларын формалаштыруга һәм әзерләүгә методик таләпләр.

Проектны эшләгәндә расланган шәһәр төзелеше документлары кулланылды: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 21.02.2011 ел, №134 карары белән расланган Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы; Түбән Кама муниципаль районы советының «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 29.04.2011 ел, №15 карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасы; Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планы, ул Түбән Кама шәһәр советының

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы генераль планын раслау турында» 12.10.2022 ел, №42 карары белән расланган; Түбән Кама шәһәр советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен яңа редакциядә раслау турында» 28.03.2024 ел, №10 карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре; һәм күчемсез мөлкәтнең дәүләт реестры һәм дәүләт урман реестры белешмәләре. Эшләр МСК-16 җирле координаталар системасында һәм Балтыйк биеклекләре системасында башкарылды.

# 1 бүлек. Территорияне планлаштыру проекты.
# График өлеше





Примечание:

1. Реконструкция линейных объектов не предусмотрена, поэтому чертеж зон планируемого размещения линейных объектов, подлежащих реконструкции в связи с изменением их местоположения, не требуется.
2. Проект не определяет границы территорий общего пользования, поэтому красные линии не устанавливаются, на территории зоны планируемого размещения линейных объектов отсутствуют существующие красные линии.
3. На территории зоны планируемого размещения линейных объектов отсутствуют земельные участки, образование которых предусмотрено схемой расположения земельного участка или земельных участков на кадастровом плане территории, срок действия которой не истек.
4. Границы существующих элементов планировочной структуры отображены на основании генерального плана муниципального образования «город Нижнекамск» Республики Татарстан, утвержденного решением Нижнекамского городского Совета от 12.10.2022 № 42 «Об утверждении Генерального плана муниципального образования город Нижнекамск Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан».

Условные обозначения:

- границы территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки
- границы зон планируемого размещения линейных объектов
- границы населенного пункта

| Кол.уч. | Лист | Nдок. | Подпись | Дата | Проект планировки и межевания территории | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | «Эстакада с общезаводскими технологическими трубопроводами, паропроводами, стыковка установки ТФК-1000 с тит.070(0914) (тит.067/5(9903))» | | |
| Директор | Галявов Р.Г. | | | | Раздел 1. "Проект планировки территории. Графическая часть" | Стадия | Лист | Листов |
| Исполнитель | Гарайшин И.М. | | | | | ПП | 1 | 3 |
| Исполнитель | Низамов А.И. | | | | Чертеж границ зон планируемого размещения линейных объектов. Масштаб 1:10000 | ООО "Кадастровый центр "Недвижимость"" | |




Условные обозначения:

- — границы территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки
- — границы зон планируемого размещения линейных объектов
- ● — поворотная точка границы

3


| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Кол.уч. | Лист | Nдок. | Подпись | Дата |
| Директор | Газябов Р.Г. | | | | |
| Исполнитель | Гарайшин М.М. | | | | |
| Исполнитель | Низамов А.И. | | | | |

Проект планировки и межевания территории

«Эстакада с общезаводскими технологическими трубопроводами, паропроводами, стыковка установки ТФК-1000 с тит.070(0914) (тит.067/5(9903))»

| Раздел 1. "Проект планировки территории. Графическая часть" | Стадия | Лист | Листов |
|---|---|---|---|
| | ПП | 2 | 3 |
| Чертеж границ зон планируемого размещения линейных объектов. Масштаб 1:2000 | ООО "Кадастровый центр "Недвижимость" | | |

Взам. инв. N
Подп. и дата
Инв. N подл.




| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Кол.уч. | Лист | Nдок. | Подпись | Дата |
| Директор | | Галявов Р.Г. | | | |
| Исполнитель | | Гарайшин М.М. | | | |
| Исполнитель | | Низамов А.И. | | | |

Проект планировки и межевания территории

«Эстакада с общезаводскими технологическими трубопроводами, паропроводами, стыковка установки ТФК-1000 с тит.070(0914) (тит.067/5(9903))»

| Р зздел 1. "Проект планировки территории. Графическая часть" | Стадия | Лист | Листов |
|---|---|---|---|
| | ПП | 3 | 3 |

Чертеж границ зон планируемого размещения линейных объектов. Масштаб 1:2000

ООО "Кадастровый центр "Недвижимость"

Взам. инв. N° | Подп. и дата | Инв. N° подл.

## 2 бүлек. Линия объектларын урнаштыру турында нигезләмә

### 2.1 Урнаштыру өчен планлаштырыла торган линия объектларының, шулай ук урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларының исеме, төп характеристикалары һәм билгеләнеше.

Планлаштырыла торган линия объектларының атамасы: «Гомумзавод технологик торбаүткәргечләре, парүткәргечләре белән эстакада, ТФК-1000 җайланмасын тит.070(0914) (тит.067/5(9903)) белән тоташтыру»

Эстакада «ТАНЕКО» АҖ чигеннән алып «ТФК-1000» мәйданчыгына кадәр тоташтыру торбаүткәргечләрен һәм кабель челтәрләрен салу өчен каралган. тит. 070 (секция 0914) белән бергә бердәм төзелеш объектын тәшкил итә.

Эстакаданың характеристикалары:

- озынлыгы - 720 м;
- киңлеге - 7,5 м;
- биеклеге - алмашынучан;
- торба үткәргеч ярусларның саны - 2;
- саны кабельле яруслар – 0 (кабельләр эстакада кырыенда урнаша);
- җаваплылык дәрәҗәсе - югары;
- төп таяныч конструкцияләр материалы - металл;
- ярдәмче конструкцияләр материалы - металл/стеклокомпозит;
- фундаментлар - субайлы нигездәге монолит тимер-бетон ростверкалар;
- торбаүткәргечләр саны - 22 данә;
- каләм ярусы колонналарының утка чыдамлылыгының таләп ителгән чиге - R60;
- каркасның башка тотучы элементларының утка чыдамлыгының таләп ителгән чиге - R 45;
- технологик ярус һәм эстакаданың ян-ягындагы кабельләр саклагыч экран белән бүленгән.

## 2.2 Территорияләрендә линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары билгеләнә торган Россия Федерациясе субъектлары исемлеге, Россия Федерациясе субъектлары составындагы муниципаль районнар, шәһәр округлары исемлеге, федераль әһәмияттәге шәһәрләрнең җирлекләре, торак пунктлары, шәһәр эчендәге территорияләре исемлеге

Линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары Россия Федерациясе Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында – «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан. Күчемсез мөлкәтнең бердә дәүләт реестры мәгълүматларына караганда, «Гомумзавод технологик торбаүткәргечләре, парүткәргечләре белән эстакада, ТФК-1000 җайланмасын тит.070(0914) (тит.067/5(9903)) белән тоташтыру» объектын 16:30:011701 кадастр кварталында урнаштыру планлаштырыла.

Линия объектларын планлаштырып урнаштыру зонасының күзәтү схемасы «Линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең сызымы» 1 бүлегенең 1 битендә китерелгән.

## 2.3 Линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге

Проектлана торган линия объектларын төзү һәм эксплуатацияләү чорына линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге 1.3 нче таблицада бирелгән.

1.3 нче таблица

| Нокта номеры | Координаталар, м | |
|---|---|---|
| | X | Y |
| 1 | 450858,17 | 2293310,12 |
| 2 | 450822,96 | 2293309,60 |
| 3 | 450812,32 | 2294031,31 |
| 4 | 450847,47 | 2294031,80 |
| 1 | 450858,17 | 2293310,12 |

## 2.4 Линия объектларының урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге

Әлеге проектта урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектлары юк, шуңа күрә аларны планлаштырып урнаштыру зоналарының чикләре билгеләнми.

## 2.5 Планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрендә линия объектлары составына керүче капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрлары

Линия объектын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрендә Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен яңа редакциядә раслау турында» 28.03.2024 ел, №10 карары белән расланган Россия Федерациясе Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән капиталь төзелешнең линия объектларын төзүнең һәм реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрлары билгеләнмәгән.

Территорияне планлаштыру проекты чикләрендә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектлары юк, шуңа бәйле рәвештә капиталь төзелеш объектларын төзүнең рөхсәт ителгән чик параметрлары билгеләнми.

**2.6 Территорияне планлаштыру проектын әзерләү вакытына гамәлдә булган һәм төзелә торган капиталь төзелешнең сакланып калучы объектларын, шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документлар нигезендә төзелергә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларын линия объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат**

«Гомумзавод технологик торбаүткәргечләре, парүткәргечләре белән эстакада, ТФК-1000 җайланмасын тит.070(0914) (тит.067/5(9903)) белән тоташтыру» проектында төзелгән территориядә объектлар төзү каралган. Планлаштырыла торган һәм гамәлдәге объектларны чикләүдә проектлана торган корылмаларның төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, эксплуатацияләү шартлары таләпләренә туры китереп конструктив карарлары кабул ителде. Линия объектларын планлаштырып урнаштыру зонасында төзелүче объектлар юк.

**2.7 Линия объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклап калу чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 17.04.2024 ел, №01-04/2050 һәм 17.07.2024 ел, №01-02/3888 номерлы бәяләмәләре нигезендә проект (объект) буенча сорала торган җирләрдә Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары юк, шуңа күрә мәдәни мирас объектларын саклау чаралары каралмаган.

## 2.8 Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Күздә тотылган төзелеш территориясендә һәм янәшәдәге территориядә куркыныч табигать процесслары (тектоник процесслар, карст, суффозия) табылмады, җир өслегенең техноген деформацияләре юк, барлык объектлар янына килү һәм технологик якын килү юллары оештырылган; Кызыл китапка кертелгән үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы вәкилләре, хайваннарның миграция юллары, ресурсларның аучылык төрләре вәкилләре һәм сирәк төр кошларның оя кору урыннары табылмады; җитештерү һәм куллану калдыкларын саклау өчен санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән урыннар теркәлмәде; төзелеш мәйданчыкларының нефть һәм нефть продуктлары белән пычрануы, шулай ук нефть продуктларының эмульсия элпәсе күренешләре су агымнарында визуаль рәвештә табылмады.

Төзелеш чорында атмосфера һавасының пычрануы төзелештә эшләүче автотранспорт һәм махсус техникадан җир, эретеп ябыштыру эшләрен башкарганда, дизель электр станцияләре эшләгәндә, техникага ягулык салганда пычраткыч матдәләр чыгару хисабына булачак.

Җир эшләре, махсус техника, эретеп ябыштыру мәйданчыклары пычраткыч матдәләрне бүлеп чыгаруның оештырылмаган чыганаклары булачак. Һаваның пычрану дәрәҗәсе атмосфераның җир өсте катламында пычраткыч матдәләрнең таралуына комачаулый торган һәм туплануына китерә торган уңайсыз метеорологик вәзгыятьләрнең (штиль, томан, температура инверсияләре) күләменә һәм үсешенә бәйле. Эксплуатация чорында проектлана торган объектлар атмосфера һавасына йогынты ясау чыганагы булып тормый.

Эшләр уздыру этабында атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруны киметү чаралары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: төзелеш процессында сыйфат сертификаты булган матдәләрне, төзелеш материалларын куллану; учаклар ягуны һәм аларда теләсә нинди төр материалларны һәм калдыкларны яндыруны тыю; подрядчы көче белән автотранспорт һәм төзелеш техникасыннан чыккан матдәләргә даими экологик контроль үткәрү; чыгарылган матдәләре норматив рөхсәт ителгәннән артмаган җиһазларны куллану; табигатьне саклау законнарын бозуның барлык очракларына оператив җавап бирү.

Эшләр башкарылган зонада атмосфера һавасын саклауга юнәлдерелгән түбәндәге табигатьне саклау чаралары күздә тотыла: автотранспорттан һәм төзелеш техникасыннан пычраткыч матдәләр чыгару күрсәткечләрен исәп-хисап чикләрендә тотып калу өчен ягулык бирүне тулысынча яндыруны тәэмин итә торган (подрядчы көче белән) механизмнарның ягулык системасын,

шулай ук ягулык бирүне җайга салу системасын контрольдә тоту; төзек хәлдәге машиналарны һәм механизмнарны эксплуатацияләүгә кертү; табигый үсемлекләрне яндырырга сәләтле техник чараларның торышын тикшереп тору.

Атмосфера бары тик эш башкару чорында гына пычрана һәм вакытлыча гына булып тора. Штатлы эксплуатация вакытында атмосфера һавасына матдәләр чыгарылмый.

Төзелеш эшләре нәтиҗәсендә өске агынтыга (агынты булган очракта) түбәндәге тискәре йогынты ясалырга мөмкин: туфракның нефть һәм нефть продуктлары белән пычрануы (техниканы файдаланганда һәм ремонтлаганда ягулык-майлау материаллары агып чыгу), үлчәүдәге матдәләр арту, шулай ук башка пычраткыч матдәләр күләменең артуы (эретеп ябыштыру эшләре аркасында); суның сыйфаты начараю; өске агымның бозылуы; территориянең калдыклар белән чүпләнүе; пычранган агынтыларны урын рельефына агызу; атмосфера явым-төшемнәре белән территориядән пычраткыч матдәләрнең юылып төшүе; авария хәлләрендә су объектларын пычрату; хуҗалык һәм җитештерү ихтыяҗлары өчен су алу.

Проектлана торган объектны төзегәндә һәм эксплуатацияләгәндә җир асты суларының «өстән» җитәрлек дәрәҗәдә сакланмавы нәтиҗәсендә җир асты суларына да тискәре йогынты ясарга мөмкин.

